Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге
Чыты торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

15 октябрь, 2024 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлегенең Чыты торак пунктында 2024 елның 15 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 314 (өч йөз ундүрт).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 167 (йөз алтмыш җиде).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 164 (йөз алтмыш дүрт).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 3 (өч).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2025 елда Чыты торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнарны, студентларны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, 1750 сум күләмендә үзара салым кертүгә, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Чыты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Чыты авыл җирлеге башлыгы С.Ә. Фәйзрахманов